КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 сентябрь г.Казань № 945

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 572 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 796 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәгә, 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Премия бирү турындагы карарга, әгәр Премия бирелгән зат (затлар) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат дип танылган очракта, махсус приз, мактаулы диплом, акчалата бүләкләү тапшырылганга кадәр үзгәреш кертелергә мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче; 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче; 2021 ел, 15 февраль, 81 нче; 2021 ел, 21 июль, 636 нчы; 2021 ел, 23 октябрь, 998 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәгә, 18 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Премия бирү турындагы карарга, әгәр премия бирелгән зат (затлар) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат дип танылган очракта, махсус приз, мактаулы диплом, акчалата бүләкләү тапшырылганга кадәр үзгәреш кертелергә мөмкин.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турында» 2020 ел, 22 август, 723 нче карары белән расланган Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәгә, 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Премия бирү турындагы карарына, әгәр премия бирелгән зат (затлар) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат дип танылган очракта, акчалата бүләкләү, диплом, Премия лауреатының мактаулы билгесе һәм аның таныклыгы тапшырылганга кадәр үзгәреш кертелергә мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин